Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәге авыл җирлеге Советы

**КАРАР №2**

Рус Әшнәге авылы 2018 елның 11 гыйнвары

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын раслау турында

Җирлекнең җирле әһәмияттәге объектлары белән тәэмин ителешенең минималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсенең җыелма исәп-хисап күрсәткечләрен һәм мондый объектларның җирлек халкы өчен максималь мөмкин булган территориаль дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләрен билгеләү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8 маддәсендәге 1 өлешенең 2 пункты һәм 29.4 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Советының 2017 елның 7 ноябрендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында” 17 номерлы карары нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында 2016 елның 15 декабрендәге Килешүне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең шәһәр төзелеше проектлаштыруның кушымта итеп бирелә торган җирле нормативларын расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан) көненнән үз көченә керә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенгең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Рус Әшнәге авылы, Мәктәп урамы, 9а йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәге авыл җирлеге Башлыгы В.Һ.Хаҗиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Рус Әшнәге авыл
җирлеге Советының
2018 елның 11 гыйнварындагы
2 номерлы карары
белән расланды

# Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативлары

2018 ел

## ЭЧТӘЛЕК

1.ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР ..........................................................................................4
2.ИСӘП-ХИСАП КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕН КУЛЛАНУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ ҺӘМ ӨЛКӘСЕ ……...........................................................................................................5
3.РУС ӘШНӘГЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНӘ КЫСКАЧА СЫЙФАТЛАМА ...................... 5
4.ТӨП ӨЛЕШ ..............................................................................................................6
4.1. Авыл җирлеге халкын электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, субүлү объектлары белән минималь тәэмин ителеш дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре; мондый объектларның җирлек халкы өчен максималь мөмкин булган территориаль дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре..........................................................................6
4.2. Торак пунктлар чикләрендә автомобиль юллары һәм җирлекнең җирле әһәмияттәге объектларына, авыл җирлеге халкына караган транспорт объектлары белән тәэмин ителешнең минималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре; мондый объектларның җирлек халкы өчен максималь мөмкин булган территориаль дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре.........................................................................................8
4.3. Авыл җирлеге халкының социаль яклауга мохтаҗ гражданнарның хокукларын тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла торган торак төзелеше объектлары белән тәэмин ителешнең минималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре; мондый объектларның җирлек халкы өчен максималь рөхсәт ителә торган территория дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре ..........................................................................................8
4.4. Авыл җирлеге халкының мәдәният, гаммәви ял итү, буш вакытны уздыру өчен булган объектлары белән тәэмин ителешнең минималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре; мондый объектларның җирлек халкы өчен максималь мөмкин булган территориаль дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре .......................................................9
4.5. Авыл җирлеге халкының физик культура һәм гаммәви спорт объектлары белән тәэмин ителешенең мөмкин булган минималь дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре; мондый объектларның җирлек халкы өчен максималь мөмкин булган территориаль дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре .............................................................. …..............................9
4.6. Авыл җирлеге халкының мәгълүматлаштыру һәм элемтә объектлары белән минималь тәэмин ителеш дәрәҗәсенең исәп күрсәткечләре; мондый объектларның җирлек халкы өчен максималь мөмкин булган территориаль дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре......10
4.7. Авыл җирлеге халкының көнкүреш калдыкларын җыю һәм алып китү объектлары белән минималь тәэмин ителешенең исәп-хисап күрсәткечләре; мондый объектларның җирлек халкы өчен максималь мөмкин булган территориаль дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре ..........................................................................................................10
4.8. Авыл җирлеген төзекләндерү һәм яшелләндерү объектлары белән ителешенең мөмкин булган минималь дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре; мондый объектларның җирлек

халкы өчен максималь мөмкин булган территориаль дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре......................................................................................................................10
4.9. Авыл җирлеге халкының ритуаль хезмәт күрсәтүләре объектлары белән тәэмин ителешенең минималь мөмкин булган дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре; мондый объектларның җирлек халкы өчен максималь мөмкин булган территориаль дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре .............................................................................................11
4.10. Авыл җирлеге халкын социаль тәэмин итү һәм социаль яклау объектлары белән тәэмин ителешенең мөмкин булган минималь дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре; мондый объектларның җирлек халкы өчен максималь мөмкин булган территориаль дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре.........................................................................11
5. АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ХАЛКЫНЫҢ ҖИРЛЕ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ОБЪЕКТЛАРГА БУЛГАН НОРМАТИВ ИХТЫЯҖЫН БИЛГЕЛӘҮГӘ, ӘЛЕГЕ ОБЪЕКТЛАРНЫ УРНАШТЫРУГА ТӘКЪДИМНӘР.......................................................................................................11
5.1. Авыл җирлеге халкының электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, субүлү объектларына норматив ихтыяҗын билгеләүгә, әлеге объектларны урнаштыру буенча тәкъдимнәр.......................................................................................................................11
5.2. Авыл җирлеге халкының торак пунктлар чикләрендә урнашкан транспорт объектларына норматив ихтыяҗын билгеләүгә, әлеге объектларны урнаштыру буенча тәкъдимнәр.......................................................................................................................14
5.3. Торак төзелеше объектларын урнаштыру буенча тәкъдимнәр......................................14
5.4. Авыл җирлеге халкының мәдәният, гаммәви ял, буш вакытны уздыру, физик культура һәм гаммәви спорт объектларына норматив ихтыяҗын билгеләү, әлеге объектларны урнаштыру буенча тәкъдимнәр..........................................................................15
5.5. Мәгълүматлаштыру һәм элемтә объектларын урнаштыру буенча тәкъдимнәр.......................................................................................................................15
5.6. Авыл җирлеге халкының көнкүреш калдыкларын җыю һәм чыгару объектларына норматив ихтыяҗын билгеләү,әлеге объектларны урнаштырубуенча тәкъдимнәр...........16
5.7. Авыл җирлеге халкының төзекләндерү һәм яшелләндерү объектларына норматив ихтыяҗын билгеләү, әлеге объектларны урнаштыру буенча тәкъдимнәр..........................17
5.8.Зиратларны урнаштыру буенча тәкъдимнәр .........................................17
6. ИСӘП-ХИСАП КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕН НИГЕЗЛӘҮ БУЕНЧА МАТЕРИАЛЛАР.......................................................................................................18

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативлары (алга таба-нормативлар) Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының норматив-хокукый актлары нигезендә эшләнде.

1.2. Әлеге нормативлар белән җайга салынмаган мәсьәләләр “Техник җайга салу турында” 27.12.2002 ел, № 184-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә, Россия Федерациясе территориясендә гамәлдә булган законнар һәм норматив-техник документлар белән җайга салына.

1.3. Әлеге нормативлар, оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Рус Әшнәге авыл җирлеге территориясендә үз эшчәнлеген алып баручы барлык шәһәр төзелеше эшчәнлеге субъектлары өчен мәҗбүри.

1.4. Шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын раслау, аларга үзгәрешләр кертү федераль законнар, Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.5. Әлеге нормативлар авыл җирлеге халкының җирле әһәмияттәге объектлар белән тәэмин ителешенең минималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре,

мондый объектларның җирлек халкы өчен максималь мөмкин булган территориаль дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре җыелмасын билгели.
1.6. Авыл җирлеге халкының тәэмин ителешенең минималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре һәм авыл җирлеге халкы өчен мондый объектларның территориаль яктан мөмкин булган кадәр мөмкин булган максималь дәрәҗәдә файдаланылуының исәп-хисап күрсәткечләре билгеләнә торган җирле әһәмияттәге объектларга түбәндәге өлкәләргә караган объектлар керә:
халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, субүлү;
авыл җирлекләре чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юллары, җирлекнең җирле әһәмияттәге транспорт объектлары;
социаль яклауга мохтаҗ гражданнарның хокукларын тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла торган торак төзелеше;
мәдәният, гаммәви ял, буш вакытны уздыру өчен булган;
мәгълүматлаштыру һәм элемтә;
физик культура һәм гаммәви спорт;
көнкүреш калдыкларын җыю һәм чыгару;
төзекләндерү һәм яшелләндерү;
ритуаль хезмәтләр күрсәтү;
социаль тәэминат һәм социаль яклау.
1.7. Нормативлар үз эченә түбәндәге өлешләрне ала:
төп өлеш (авыл җирлеге халкының җирле әһәмияттәге объектлар белән тәэмин ителешенең минималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре; мондый объектларның җирлек халкы өчен максималь мөмкин булган территориаль дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре);
нормативларның төп өлешендә булган исәп-хисап күрсәткечләрен нигезләү буенча материаллар;
нормативларның төп өлешендә булган исәп-хисап күрсәткечләрен куллану кагыйдәләре һәм өлкәсе;
авыл җирлеге халкының җирле әһәмияттәге объектларга булган ихтыяҗын билгеләү буенча, әлеге объектларны урнаштыру буенча тәкъдимнәр;
авыл җирлегенә кыскача сыйфатлама.

## 2. ИСӘП-ХИСАП КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕН КУЛЛАНУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ ҺӘМ ӨЛКӘСЕ

2.1. Рус Әшнәге авыл җирлегенең территориаль планлаштыру документларын, Рус Әшнәге авыл җирлеге территорияләренә карата эшләнелә торган территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү, килештерү, раслау һәм тормышка ашыру вакытында әлеге нормативлар белән билгеләнә торган исәп-хисап күрсәткечләре кулланыла.
2.2. Шәһәр төзелешен проектлаштыру нормативлары дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору һәм күзәтү органнары тарафыннан карарлар кабул итү өчен кулланыла.
2.3. Җирлекнең җирле әһәмияттәге объектлары исемлеге, әлеге нормативларның төп өлешендә китерелгән авыл җирлеге халкының җирле әһәмияттәге объектлар белән тәэмин ителешенең минималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре һәм мондый объектларның җирлек халкы өчен максималь мцмкин булган территориаль дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре үтәү мәҗбүри булып тора.
2.4. Гамәлдәге норматив документларны, шул исәптән әлеге нормативларда сылтама бирелгәннәрне гамәлдән чыгарганда һәм (яисә) үзгәрткәндә, алмашка кертелгән нормаларга таянып эш итәргә кирәк.

## 3. РУС ӘШНӘГЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНӘ КЫСКАЧА СЫЙФАТЛАМА

3.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге территориясенең кыскача сыйфатламасы, шулай ук халыкның саны, тыгызлыгы

һәм социаль-демографик составы турында мәгълүматлар, җирлекнең башка аңа хас үзенчәлекләре:
Рус Әшнәге авыл җирлеге “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында” 2005 елның 31 гыйнварындагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә төзелде.
Рус Әшнәге авыл җирлеге Балык Бистәсе муниципаль районының көнбатыш өлешендә урнашкан.

Рус Әшнәге авыл җирлеге төньякта – Олы Әшнәк авыл җирлеге, көнчыгышта – Анатыш, көнбатышта – Олы Елга авыл җирлеге, көньякта Масловка авыл җирлеге белән чиктәш. Рус Әшнәге авыл җирлегенең мәйданы -141,0 га.

***Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең перспективадагы халык саны (кеше)***

| Территориянең аталышы | 2017 ел | 2020 ел | 2030 ел |
|---|---|---|---|
| Рус Әшнәге авыл җирлеге | **540** | **479** | **444** |
| Рус Әшнәге авылы | 540 | 479 | 444 |

### 3.2 Торак төзелеше

Муниципаль районда авария хәлендәге торакны бетерү программасы расланды, гражданнарны ипотека буенча кредитлау темпы арта бара.

Муниципаль районның үсеш перспективасы гамәлдәге уникаль производстволарны үстерү белән һәм туризм, торак, юллар төзелеше, торак-коммуналь өлкәдә базар мөнәсәбәтләре булдыру кебек өлкәләр белән бәйле, бу исә районның торак-коммуналь хуҗалыгын модернизацияләү зарурлыгына бәйле.
Рус Әшнәге авыл җирлегенең гамәлдәге төзелеше йорт яны җир кишәрлекләре белән шәхси торак йортлардан гыйбарәт. 2017 елның 1 гыйнварына торак фондының гомуми мәйданы 14,07 мең кв. м тәшкил итә.
Халыкны торак белән тәэмин итү 26,06 кв. м тәшкил итә.
ТР буенча уртача күрсәткеч 24.3 кв. м тәшкил итә.

### 3.3 Социаль өлкә

Социаль өлкә объектлары шулай ук коммуналь хезмәтләрне кулланучылар булып тора.

### 3.4 Мәдәният объектлары.

Рус әшнәсе авыл җирлегендә мәдәният объектлары булып мәдәният йорты һәм китапханә санала.

## 4. ТӨП ӨЛЕШ

4.1. Авыл җирлеге халкын электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, субүлү объектлары белән тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре; мондый объектларның җирлек халкы өчен максималь мөмкин булган территория дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре.
4.1.1Торак пунктларны төзүнең инженерлык җиһазлары системаларын билгеләнгән тәртиптә эшләнгән һәм расланган авыл җирлеген территориаль планлаштыру документлары һәм су белән тәэмин итү, канализация, электр, җылылык һәм газ белән тәэмин итү схемалары нигезендә проектлаштырырга кирәк.

Әлеге тармак схемаларында технологиянең, куәтнең, инженерлык челтәрләре күләменең принципиаль мәсьәләләре хәл ителергә, схеманы тормышка ашыру чираты буенча тәкъдимнәр бирелергә тиеш.
4.1.2. Күрсәтелгән исәп-хисап күрсәткечләре 2 нче таблицада китерелгән. Таблица 2

| № п/п | Объектның аталышы | Халыкның минималь рөхсәт ителгән тәэмин ителеше дәрәҗәсе | җирлек халкы өчен максималь мцмкин булган территориаль дәрәҗәсе |
|---|---|---|---|
| 1 | Электр белән тәэмин итү системасы объектлары: электр трансформатор подстанцияләре, бүлү пунктлары, төрле көчәнешләрдәге электр челтәрләре | Торак һәм җәмәгать биналарының электр энергиясе белән 100 процент тәэмин ителеше; торак урамнарның 100 процент яктыртылышы | билгеләнми |
| 2 | Җылылык белән тәэмин итү системасы объектлары, шул исәптән: үзәкләштерелгән: котельныйлар, җылылык электр станцияләре, җылылык челтәрләре; үзәктән аерылган: автоном һәм индивидуаль котельныйлар, фатир җылылык генераторлары, җылылык челтәрләре | Торак һәм җәмәгать биналарының җылылык энергиясе белән 100 процент тәэмин ителеше | билгеләнми |
| 3 | Үзәкләштерелгән газ белән тәэмин итү системасы объектлары: газ бүлү һәм газ тутыру станцияләре һәм пунктлары, газ көйләү пунктлары; газ бүлү челтәрләре | Торак биналарны газ белән 100 процент тәэмин итү | билгеләнми |
| 4 | Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системасы объектлары: су белән тәэмин итү чыганаклары, су җыю корылмалары, су саклау өчен сыешлык, суүткәргечләр | Торак һәм җәмәгать биналарын су белән 100 процент тәэмин итү | билгеләнми |
| 5 | Субүлү системасы объектлары*, шул исәптән: үзәкләштерелгән: чистарту корылмалары, канализация насос | Торак һәм җәмәгать биналарының 100 процент тәэмин ителеше | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | станцияләре, канализация торбаүткәргечләре; үзәктән аерылган: локаль чистарту корылмалары, агызу станцияләре, канализация торбаүткәргечләре | | билгеләнми |

* исәп-хисап күрсәткечләре яңгыр сулары канализациясенә кагылмый

**4.2. Торак пунктлар чикләрендә автомобиль юллары һәм җирлекнең, авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге объектларына караган транспорт объектлары белән тәэмин ителешнең минималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре; мондый объектларның җирлек халкы өчен максималь мөмкин булган территория дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре.**

4.2.1. Автомобиль транспорты барлык биналарга һәм корылмаларга да барып җитәрлек (үтәрлек) булырга тиеш.

4.2.2. Авыл җирлеге халкы өчен җәмәгать пассажир транспорты тукталыш пунктларының территориаль яктан файдалану мөмкинлегенең максималь дәрәҗәдә мөмкин булган күрсәткечен 3 нче таблица нигезендә кабул итәргә кирәк. Авыл җирлеге халкының әлеге объектлар белән тәэмин ителешенең мөмкин булган минималь дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре билгеләнми.

Таблица 3

| № п/п | Объектның аталышы | Халык өчен территориаль мөмкинлекләрнең максималь мөмкин булган дәрәҗәсе (метрлар) |
|---|---|---|
| 1 | Тукталыш пунктлары, тулаем алганда, торак пункт буенча | 500 |

**4.3. Авыл җирлеге халкының социаль яклауга мохтаҗ гражданнарның хокукларын тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла торган торак төзелеше объектлары белән тәэмин ителешнең минималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре; мондый объектларның җирлек халкы өчен максималь мөмкин булган территория дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре**

4.3.1. Күрсәтелгән исәп-хисап күрсәткечләрен 4 нче таблица нигезендә кабул итәргә кирәк.

Таблица 4

| № п/п | Объектның аталышы | Халыкның тәэмин ителешенең минималь мөмкин булган дәрәҗәсе (кв. м/кеше) 2017 ел | Халыкның тәэмин ителешенең минималь мөмкин булган дәрәҗәсе (кв. м/кеше) 2025 ел | Халык өчен территориаль мөмкинлекләрнең максималь мөмкин булган дәрәҗәсе |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Халык өчен территориаль мөмкинлекләрнең максималь мөмкин булган | 26,06 | 27,4 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | дәрәҗәсе | | | билгеләнми |

Искәрмә.
Киләчәккә исәпләнгән күрсәткечләр 2025, 2035 елларда ирешелгән торак урыннарның гомуми мәйданы белән тәэмин ителешнең факттагы минималь дәрәҗәсен исәпкә алып төзәтелә.

**4.4. Авыл җирлеге халкының мәдәният, гаммәви ял итү, буш вакытын уздыру объектлары белән минималь тәэмин ителеш дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре; мондый объектларның җирлек халкы өчен максималь мөмкин булган территория дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре**

4.4.1. Күрсәтелгән исәп-хисап күрсәткечләрен 5 нче таблица нигезендә кабул итәргә кирәк.

Таблица 5

| № п/ | Объектның аталышы | Халыкның тәэмин ителешенең минималь мөмкин булган дәрәҗәсе | Халык өчен территориаль мөмкинлекләрнең максималь мөмкин булган дәрәҗәсе |
|---|---|---|---|
| 1 | Халык саны түбәндәгечә булган торак пунктлар өчен клуб учреждениеләре:<br>0,2 – 1 мең кеше<br><br>1 – 3 мең кеше | <br><br><br>300 урын<br><br>300 – 230 урын | билгеләнми |
| 2 | Халык саны түбәндәгечә булган авыл торак пунктлары өчен авыл китапханәсе: 1 – 3 мең кеше | 6 - 7,5 мең саклау берәмлеге;<br>1000 кешегә 5 - 6 урын. | билгеләнми |

Искәрмә.
1. Азрак исәп-хисап күрсәткечен зур торак пунктлар өчен кабул итәргә кирәк.
2. Халык саны 1,5 меңнән артык булган авыл торак пунктлары (район үзәкләре һәм ярдәмче үзәкләр) өчен объектларның санын, составын һәм сыйдырышлылыгын билгеләгәндә, 30 минутлык җәяүлеләр йөри алырлык зонада урнашкан башка торак пунктлардан килгән халыкны өстәмә рәвештә исәпкә алырга кирәк.
3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 26.01.2009 ел 42 номерлы карары нигезендә, 2019 елга кадәр клуб учреждениеләре һәм китапханә хезмәтләре белән тәэмин ителешнең социаль гарантияләре дәрәҗәсе гамәлдәге тәэмин ителеш дәрәҗәсендә кабул ителә.

**4.5. Авыл җирлеге халкының физик культура һәм массакүләм спорт объектлары белән тәэмин ителешенең минималь мөмкин булган дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре; мондый объектларның җирлек халкы өчен максималь мөмкин булган территория дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре**

4.5.1. Күрсәтелгән исәп-хисап күрсәткечләрен 6 таблица нигезендә кабул итәргә кирәк.

Таблица 6

| № п/п | Объектның аталышы | Халыкның тәэмин ителешенең минималь мөмкин булган дәрәҗәсе | Халык өчен территориаль мөмкинлекләрнең максималь мөмкин булган дәрәҗәсе |
|---|---|---|---|
| 1 | Спорт заллары | 1000 кешегә 350 кв.м | билгеләнми |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 | Яссы спорт корылмалары | 1000 кешегә 1950кв.м. | билгеләнми |

**4.6. Авыл җирлеге халкын мәгълүматлаштыру һәм элемтә объектлары белән тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре; мондый объектларның җирлек халкы өчен максималь мөмкин булган территория дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре**

4.6.1. Авыл җирлеге халкын мәгълүматлаштыру һәм элемтә объектлары белән тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләрен 7 нче таблица нигезендә кабул итәргә кирәк.

Таблица 7

| № п/п | Объектның аталышы | Үлчәү берәмлеге | Халыкның тәэмин ителешенең минималь мөмкин булган дәрәҗәсе |
|---|---|---|---|
| 1 | Почта элемтәсе бүлекчәсе | Авыл җирлегенә объектлар | 1 |

4.6.2. Авыл җирлеге халкы өчен мәгълүматлаштыру һәм элемтә объектларының территориаль яктан мөмкин булган дәрәҗәдә исәп-хисап күрсәткечләре билгеләнми.

**4.7. Авыл җирлеге халкының көнкүреш калдыкларын җыю һәм чыгару объектлары белән тәэмин ителешенең минималь мөмкин булган дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре; мондый объектларның җирлек халкы өчен максималь мөмкин булган территория дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре**

4.7.1. Көнкүреш калдыкларын җыю һәм чыгару объектлары исемлеге, мондый объектларның урнашу урыны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге территориясен санитар чистартуның Генераль схемасы нигезендә кабул ителә.

4.7.2. Авыл җирлеге халкы өчен каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнер мәйданчыкларының территория ягыннан мөмкин кадәр файдалана алырлык дәрәҗәдә үтәлү дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечен 100 метр (яшәү урыннарыннан, балалар һәм дәвалау-профилактика учреждениеләреннән, спорт мәйданчыкларыннан, ял итү урыннарыннан ераклык) күләмендә кабул итәргә кирәк.

**4.8. Авыл җирлеге халкын төзекләндерү һәм яшелләндерү объектлары белән тәэмин ителешенең минималь мөмкин булган дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре; мондый объектларның җирлек халкы өчен максималь мөмкин булган территория дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре**

4.8.1. Авыл җирлеге халкының гомуми файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләр белән тәэмин ителешенең минималь мөмкин булган дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләрен 8 нче таблица нигезендә кабул итәргә кирәк.

Таблица 8

| № п/п | Объектның аталышы | Халыкның тәэмин ителешенең минималь мөмкин булган дәрәҗәсе (кв. метр/кеше) | Халык өчен территориаль мөмкинлекләрнең максималь мөмкин булган дәрәҗәсе (кв.м/кеше) |
|---|---|---|---|
| 1 | Авыл торак пунктларында гомуми файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләр | 12 | билгеләнми |

Искәрмә.

Урманнар чолганышында, эре елгаларның һәм сулыкларның яр буе зоналарында урнашкан торак пунктлар өчен гомуми файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләрнең мәйданын киметергә мөмкин, ләкин 20 %тан да артмаслык итеп.

**4.9. Авыл җирлеге халкының ритуаль хезмәтләре күрсәтү объектлары белән тәэмин ителешенең минималь мөмкин булган дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре; мондый объектларның җирлек халкы өчен максималь мөмкин булган территория дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре**

4.9.1. Күрсәтелгән исәп-хисап күрсәткечләрен 9 таблица нигезендә кабул итәргә кирәк.

Таблица 9

| № п/п | Объектның аталышы | Халыкның тәэмин ителешенең минималь мөмкин булган дәрәҗәсе (га/1 мең кеше) | Халык өчен территориаль мөмкинлекләрнең максималь мөмкин булган дәрәҗәсе |
|---|---|---|---|
| 1 | Традицион күмү (җирләү) зираты | 0,24 | билгеләнми |

**4.10. Авыл җирлегенең социаль тәэминат һәм халыкны социаль яклау объектлары белән тәэмин ителешенең минималь мөмкин булган дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре; мондый объектларның җирлек халкы өчен максималь мөмкин булган территория дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре**

4.10.1. Инвалидларның шәхси автотранспортын даими саклау урыннары белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе җиңел автомобильләрне даими саклау урыннарының гомуми саныннан 10% ка (әмма 1 урыннан да ким түгел) тигез булырга тиеш, шул исәптән кресло-коляскада инвалидлар автотранспорты өчен махсуслаштырылган урыннарның 5 % ы. Учреждениеләр һәм хезмәт күрсәтү предприятиеләре янында җиңел автомобильләрне кыска вакытлы саклау өчен ачык мәйданчыкларда инвалидларның шәхси автотранспортын вакытлыча саклау урыннары белән халыкның тәэмин ителеш дәрәҗәсен җиңел автомобильләрне вакытлыча саклау урыннарының гомуми санының 10 % ына (әмма 1 урыннан да ким түгел) тигез итеп кабул итәргә кирәк.

## 5. АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ХАЛКЫНЫҢ ҖИРЛЕ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ОБЪЕКТЛАРГА БУЛГАН ИХТЫЯҖЫН БИЛГЕЛӘҮ, ӘЛЕГЕ ОБЪЕКТЛАРНЫ УРНАШТЫРУ БУЕНЧА ТӘКЪДИМНӘР

5.1. Авыл җирлеге халкының электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, субүлү объектларына норматив ихтыяҗын билгеләү, әлеге объектларны урнаштыру буенча тәкъдимнәр

5.1.1. Электр белән тәэмин итү системаларын проектлаштыруны уртак предприятие таләпләре нигезендә билгеләнә торган электр чыганакларына электр йөкләнеше күрсәткечләре "Торак һәм иҗтимагый биналарның электр җайланмаларын проектлаштыру һәм монтажлау" СП 31-110-2003 таләпләре (6 бүлек), "ФСК ЕЭС" ААҖнең 2006 елның 2 июнендәге техник сәясәт турындагы Нигезләмә (2 бүлек) нигезендә гамәлгә ашырырга кирәк.

Алдан исәп-хисаплар ясау өчен торак пунктлар территорияләренең чагыштырма исәп-хисап йөкләнешенең эреләнгән күрсәткечләрен 10 нчы таблица нигезендә кабул итәргә кирәк.

Таблица 10

| Халык саны (мең кеше) | Тулаем торак пункт буенча табигый газда плитәләр куелган торак пункт | Табигый газда плитәләр куелган торак пункт (кВт/кеше) үзәк | Табигый газда плитәләр куелган торак пункт (кВт/кеше) микрорайоннар/кварталлар |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| | (кВт/кеше) | | |
| 3 тән ким | 0,41 | 0,51 | 0,39 |

Искәрмә.
1 Торак пункт үзәге төшенчәсе дигәндә төрле административ, мәдәни, белем бирү учреждениеләре, сәүдә һәм җәмәгать туклануы предприятиеләре тупланган территорияне аңларга кирәк.
2. Таблицада вак сәнәгать предприятиеләреннән йөкләнеш исәпкә алынмаган. Аларны исәпкә алу өчен түбәндәге коэффициентларны кулланырга кирәк:
табигый газда плитәләр куелган торак пунктлар өчен: 1,2-1,6.
Торак пункт үзәге территориясенә карата зур кыйммәтләр кабул итәргә кирәк.
Электр энергиясен бүлү системасы көчәнешен сайлау перспективалы электр йөкләнешләренең үсешен анализлауны исәпкә алып, Татарстан Республикасы бүлүче электр челтәре комплексы челтәрләрен перспективалы үстерү схемасы нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш.
Торак пунктларның электр челтәрләренең көчәнеше аларны үстерүнең хисап срогы һәм энергия системасында көчәнеш системасы чикләрендә концепциясен исәпкә алып билгеләнә: 35 – 110 – 220 – 500кВ яки 35 – 110 – 330 – 750 кВ.
Электр белән тәэмин итү системасының көчәнеше энергия трансформациясенең иң аз баскычларын исәпкә алып сайланырга тиеш. Якын араларда 35 - 110/10 кВ көчәнешләр системасы аеруча максатка ярашлы.
Торак пунктлар территорияләрендә трансформатор подстанцияләрен һәм бүлү җайланмаларын проектлаштыруны “ФСК ЕЭС” ААҖнең 2006 елның 2 июнендәге техник сәясәте турындагы Нигезләмәсенең электр җайланмаларын урнаштыру кагыйдәләре таләпләре һәм 2 бүлеге нигезендә гамәлгә ашырырга кирәк.
Трансформатор подстанцияләрен, бүлү җайланмаларын һәм электр үткәргечләрнең һава линияләрен торак төзелеше территориясендә урнашкан кабельлегә күчерү пунктларын ябык типта проектлаштырырга тәкъдим ителә.
5.1.2. Яңа җылылык белән тәэмин итү системаларын проектлаштыру һәм төзү, гамәлдәге җылылык белән тәэмин итү системаларын реконструкцияләү һәм үстерү авыл җирлеген җылылык белән тәэмин итүнең расланган схемасы нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш.
Җылылык белән тәэмин итү системаларын проектлаштыруны җылылык белән тәэмин итүнең ышанычлылыгы буенча кулланучылар категорияләрен исәпкә алып, “Җылылык челтәрләре” СНиП 41-02-2003 (5 бүлек), ГОСТ Р 54964-2012 “Тәнгәллекне бәяләү” исәп-хисаплы җылылык йөкләнешләре күрсәткечләре нигезендә башкарырга кирәк,
“Күчемсез милек объектларына экологик таләпләр”(А кушымтасы).
Торак пунктлар территорияләрендә җылылык белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән чыганакларын коммуналь-склад һәм житештерү зоналарына, җылылык йөкләнешләре үзәкләренә урнаштырырга тәкъдим ителә.
Җылылык белән тәэмин итү чыганакларын, җылылык пунктларын урнаштыру акустик исәпләүләр белән нигезләнгән булырга тиеш.
Җылылык челтәрләрен сузу трассалары һәм ысуллары СНиП 41-02-2003 “Җылылык челтәрләре” таләпләре нигезендә (9 бүлек) каралган, СП 42.13330.2011 СНиП актуаль редакциясе 2.07.01-89*. “Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү" (12 бүлек).
5.1.3. Газ белән тәэмин итүнең гамәлдәге системаларын проектлаштыру һәм төзү, реконструкцияләү һәм үстерүне ПБ 12-529-03 “Газ бүлү һәм газ куллану системаларының куркынычсызлыгы кагыйдәләре”нә, СНиП 42-01-2002 ”Газ бүлү системалары” таләпләренә туры китереп Татарстан республикасын газлаштыру һәм газ белән тәэмин итүнең генераль схемасы нигезендә, торак-коммуналь хуҗалыкны, сәнәгать һәм башка оешмаларны газлаштыру буенча республика программалары нигезендә башкарырга кирәк.

Авыл торак пунктлары өчен газ куллануның бер кешегә елына 220 куб. м күләмендә эреләндерелгән (берләштерелгән) күрсәткечен кабул итәргә кирәк.
Газ бүлү һәм газ тутыру станцияләре торак пунктлардан читтә урнаштырылырга тиеш. Газ тутыру пунктларын торак пунктның торак төзелеше территориясеннән читтә, арткы якта урнаштырырга кирәк.

Газ бүлү челтәрендә газ басымын киметү һәм җайга салу өчен газны көйләү (блоклы яки шкафлы) пунктларын проектларга кирәк.
Газорегуляторный пункт следует размещать в центре района его действия, максимально близко к центру нагрузки района. Газ көйләү пунктын газ хәрәкәте өлкәсе үзәгендә урнаштырырга кирәк, ул йөкләнеш үзәгенә мөмкин кадәр якын булсын.
Торак пунктларда аерым торучы газны җайга салучы (көйләү) пунктларны биналар һәм корылмаларга кадәр билгеле бер ераклыкта урнаштырырга кирәк:
газ көйләү пунктына кергәндә газ басымы 0,6 МПа булганда – 10 метрга кадәр;
газ көйләү пунктына кергәндә газ басымы 0,6 – 1,2 МПа булганда – 15 метр.
5.1.4. Торак пунктларны су белән тәэмин итү системаларын проектлаштыру, шул исәптән су белән тәэмин итү чыганакларын сайлау, су алу корылмаларын урнаштыруны түбәндәгеләр таләпләренә туры китереп башкарырга кирәк: СП 30.13330.2012 Актуальләштерелгән редакция СНиП 2.04.01-85*" Биналарның эчке суүткәргечләре һәм канализациясе", СП 31.13330.2012 Актуальләштерелгән редакция СНиП 2.04.02-84* "Су белән тәэмин итү. Тышкы челтәрләр һәм корылмалар", СП 42.13330.2011

Актуальләштерелгән редакция СНиП 2.07.01-89*. "Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү" (12 бүлек), СанПиН 2.1.4.1074-01 "Эчәргә яраклы су. Эчә торган су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системаларының сыйфатына карата гигиена таләпләре. Сыйфатка контроль. Кайнар су белән тәэмин итү системаларының иминлеген тәэмин итүгә гигиена таләпләре", СанПиН 2.1.4.1175-02 "Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү сыйфатына карата гигиена таләпләре. Чыганакларны санитар саклау», ГОСТ 2761-84* "Үзәкләштерелгән көнкүреш-эчә торган су белән тәэмин итү чыганаклары. Гигиеник, техник таләпләр һәм сайлау кагыйдәләре", СанПиН 2.1.4.1110-02 "Су белән тәэмин итү һәм эчәргә яраклы суүткәргечләр чыганакларын санитар саклау зоналары".
Халыкның көнкүреш-эчә торган ихтыяҗлары өчен тәүлеккә уртача (бер елга) су куллануның эреләндерелгән (берләштерелгән) чагыштырма күрсәткечен бер кешегә тәүлегенә 200 литр күләмендә кабул итәргә кирәк (эчке суүткәргеч һәм канализация белән җиһазландырылган, ванна һәм җирле су җылыткычлары булган биналар өчен).
Су җыю корылмаларының типларын һәм урнашу схемасын сайлауны территориянең геологик, гидрогеологик һәм санитария шартларыннан чыгып башкарырга кирәк.
Су үткәрү челтәрләрен боҗра рщвешендщ проектлаштырырга кирәк. Суүткәргечләрнең тупик (нәрсәгәдер килеп терәлә торган) линияләрен куллану рөхсәт ителә:
авария вакытында су белән тәэмин итүдә өзеклек булган очракта җитештерү ихтыяҗларына су бирү өчен;
торбаларның диаметры 100 мм дан артмаганда көнкүреш-эчү ихтыяҗларына су бирү өчен;
линия озынлыгы 200 метрдан да артык булмаганда янгын сүндерүгә тотылучы су чыгымына бәйсез рәвештә янгынга каршы яисә хуҗалык-янгынга каршы ихтыяҗларга су бирү өчен;

Бина һәм корылмаларның эчке суүткәргеч челтәрләре белән тышкы су челтәрләрен боҗралау рөхсәт ителми.
5.1.5. Торак пунктларның канализация системаларын проектлаштыруны түбәндәге документлар таләпләренә туры китереп башкарырга кирәк: СП 30.13330.2012 Актуальләштерелгән редакция СНиП 2.04.01-85* "Биналарның эчке суүткәргече һәм канализациясе", СП 32.13330.2012 Актуальләштерелгән редакция СНиП 2.04.03-85* "Канализация. Тышкы челтәрләр һәм корылмалар", СП 42.13330.2011

Актуальләштерелгән редакция СНиП 2.07.01-89*. “Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү” (12 бүлек).
Көнкүреш юынтык суларының уртача чагыштырма тәүлеклек субүлү исәп-хисабы территориягә һәм яшел үсентеләргә су сибүне исәпкә алмыйча уртача чагыштырма тәүлеклек су куллануга тигез күләмдә кабул ителә.

Территориаль планлаштыру документларын эшләгәндә авыл торак пунктлары өчен чагыштырма тәүлеклек уртача (бер елга) су бүлүне кеше башына 150л/тәүл. итеп кабул итү рөхсәт ителә.

Агып төшүче (юынтык) суларны чистарту корылмалары мәйданчыкларын елның җылы чорында өстенлек итүче җилнең юнәлешен торак пунктның торак төзелешеннән кире якка исүне исәпкә алып су агымы буенча түбәнгәрәк урнаштырырга кирәк.

**5.2. Авыл җирлеге халкының торак пунктлар чикләрендә урнашкан транспорт объектларына, әлеге объектларны урнаштыру буенча норматив ихтыяҗын билгеләү буенча тәкъдимнәр**

5.2.1. Торак пунктлар территориясендә урамнар һәм юллар челтәренең үткәрүчәнлек мөмкинлеге автомобильләшү дәрәҗәсеннән чыгып билгеләнә.
Авыл торак пунктлары өчен 2025 елга кадәр исәпләнгән срокка автомобильләшү дәрәҗәсен 1000 кешегә 440 автомобиль туры килә кабул итәргә кирәк.
5.2.2. Урта, зур һәм эре авыл торак пунктларында төзелгән территорияләр чикләрендә магистраль урамнарда һәм юлларда җайга салына торган хәрәкәттә 200 - 300 метр интервал белән бер дәрәҗәдә җәяүле кичүләрне күздә тотарга кирәк.
5.2.3. Җәмәгать транспортының тукталыш пунктлары арасындагы ераклыкны 400 - 600 метрга тигез итеп кабул итәргә тәкъдим ителә, урта, зур һәм эре авыл торак пунктларының иҗтимагый үзәге чикләрендә - 300 метр.
5.2.4. Торак пунктлар чикләрендә автомобиль юлларын һәм җирлекнең җирле әһәмияттәге объектларына караган транспорт объектларын проектлаштыруны СП 42.13330.2011 Актуальләштерелгән редакция СНиП 2.07.01-89*. “Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү” (11 бүлек, кушымталар И, К, Л) таләпләренә туры китереп гамәлгә ашырырга кирәк.

**5.3. Торак төзелеше объектларын урнаштыруга тәкъдимнәр**

5.3.1. Торак төзелеше һәм торак төзелеше төрләре күләмнәренең исәп-хисап күрсәткечләре гамәлдәге һәм фаразланыла торган социаль-демографик вәзгыятьне һәм халыкның керем дәрәҗәсен исәпкә алып башкарылырга тиеш.
5.3.2. Торак төзелеше характеры нигезендә 11 нче таблицада китерелгән төзелеш типлары аерылып тора.
Таблица 11

| № п/п | Торак төзелеше тибы | Төзелешнең сыйфатламасы |
|---|---|---|
| 1 | Азкатлы торак төзелеше | 3 катка кадәр биеклектәге индивидуаль утар төзелеше;<br>3 катка кадәр биеклектәге блокланган торак йортлар төзелеше;<br>4 катка кадәр биеклектәге күпфатирлы торак йортлар төзелеше |
| 2 | Уртача катлы торак төзелеше | 5-8 катлы күпфатирлы торак йортлар төзелеше |
| 3 | Күпкатлы торак төзелеше | 9 катлы һәм аннан күбрәк биеклектәге күпфатирлы торак йортлар төзелеше |

Торак төзелеше төрләрен бүлеп бирү, аларны оештыруга карата таләпләрне билгеләү осуществляется правилами землепользования и застройки сельского поселения. авыл җирдән файдалану һәм авыл җирлегенең төзелеш алып бару кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.3.3. Торак пунктларда торак төзелешенең норматив параметрлары 7 нче бүлекнең СП 42.13330.2011Актуальләштерелгән редакция СНиП2.07.01-89*. "Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү" таләпләре нигезендә башкарыла.

**5.4. Авыл җирлегенең мәдәният, гаммәви ял, буш вакытны уздыру, физик культура һәм гаммәви спорт объектларына халыкның норматив ихтыяҗларын билгеләүгә, күрсәтелгән объектларны урнаштыруга тәкъдимнәр**

5.4.1. Авыл җирлегенең мәдәният, гаммәви ял, буш вакытны уздыру, физик культура һәм гаммәви спорт объектларына халыкның норматив ихтыяҗларын билгеләүне халыкның төрле социаль-демографик төркемнәре ихтыяҗларын канәгатьләндерү зарурлыгына туры китереп башкарырга кирәк.

5.4.2. Әлеге объектларны урнаштыру башка шундый ук объектларның якынлыгын, транспорт элемтәләрен оештыруны, урамнар, юллар һәм җәяүлеләр юллары челтәрләре белән үзара бәйләнештә булуны исәпкә алып башкарылырга тиеш.

5.4.3. Мәдәният, гаммәви ял, буш вакытны уздыру, физик культура һәм гаммәви спорт объектларын урнаштыру өчен җир кишәрлекләренең үлчәмнәрен проектлаштыруга бирем нигезендә кабул итәргә кирәк.

5.4.4. Физик культура һәм гаммәви спорт объектларын белем бирү мәктәпләренең һәм башка уку йортларының, ял һәм мәдәният учреждениеләренең спорт объектлары белән берләштерергә рөхсәт ителә.

**5.5. Мәгълүматлаштыру һәм элемтә объектларын урнаштыруга тәкъдимнәр**

5.5.1. Яңа төзелешне гамәлгә ашырганда телекоммуникация системаларын, эфирлы цифрлы телевидениене күмәк кабул итү системасы һәм бер үк вакытта өч элемтә операторы тарафыннан хезмәт күрсәтү өчен кирәкле булган яшерен эчке коммуникацияләр буенча йорт эчендәге элемтә челтәрләрен урнаштыруны күз алдында тотарга кирәк.

5.5.2. Мәгълүматлаштыру һәм элемтә объектларын урнаштыру өчен җир кишәрлекләре мәйданын 12 нче таблица нигезендә кабул итәргә кирәк.

Таблица 12

| № п/п | Объектның аталышы (исеме) | Кишәрлек (бүлемтек) мәйданы |
|---|---|---|
| 1 | Почта элемтәсе бүлекчәсе | 700-1200 кв.м |
| 2 | Автоматик телефон станциясе | 0,25 га |
| 3 | Автоматик телефон станциясе | 0,3га |
| 4 | Концентратор | 40-100 кв.м. |
| 5 | Терәк-көчәйтү станциясе | 0,1-0,15га |
| 6 | Чыбыклы тапшырулар блок-станциясе | 0,05-0,1га |
| 7 | Тавыш трансформатор подстанциясе | 50-70 кв.м |
| 8 | Кабельле телевидениенең техник үзәге | 0,3-0,5 га |

5.5.3. Элемтә предприятиеләре биналарын, күрше предприятиеләргә яисә технологик процесслар булган объектларга карата, җил искән якта (өстенлекле юнәлештәге җилләр өчен) урнаштырырга кирәк, чөнки ул объектлар зарарлы, коррозия-актив, начар ис килә торган матдәләр һәм тузан бүлеп чыгару чыганаклары булырга мөмкин, аларның санитар-яклау зоналарыннан читтә урнаштыру мәгъкуль.

5.5.4. Элемтә линияләрен урнаштыруны СН 461-74 “Элемтә линияләре өчен җир бүлеп бирү нормалары” таләпләре нигезендә гамәлгә ашырырга кирәк.

**5.6. Авыл җирлеге халкының көнкүреш калдыкларын җыю һәм чыгару объектларына норматив ихтыяҗын билгеләү, әлеге объектларны урнаштыру буенча тәкъдимнәр**

5.6.1. Торак пунктларның торак зоналарында автомобиль транспорты өчен подъездлар белән тәэмин ителгән каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнер мәйданчыклары урнаштыруны күздә тотарга кирәк.

Кирәкле күләмдә контейнер мәйданчыкларын билгеләү өчен, контейнерлардан файдаланучы халык саныннан, калдыкларның туплануыннан, калдыкларны саклау сроклары нормасыннан чыгып карарга кирәк. Контейнерларның исәп-хисап микъдары калдыкларның иң күп җыела торган чорында фактта туплану дәрәҗәсенә туры килергә тиеш.

5.6.2. Көнкүреш калдыкларының туалану нормалары күрсәткечләрен СП 42.13330.2011 Актуальләштерелгән редакция СНиП 2.07.01-89*. “Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү”(13 нче таблицада китерелә) таләпләренә туры китереп кабул итәргә кирәк. Җыелган көнкүреш калдыкларның микъдарын периодик рәвештә (һәр 5 ел саен) факттагы мәгълүматлар буенча аныкларга кирәк.

Таблица 13

| Көнкүреш калдыкларының төрләре | 1 кешегә көнкүреш калдыклары микъдары кг | Елына 1 кешегә көнкүреш калдыклары микъдары литр |
|---|---|---|
| Каты:<br>сууткәргеч, канализация, үзәк җылылык һәм газ белән тәэмин ителгән торак биналардан;<br>башка торак биналардан | 190-225<br>300-450 | 900-1000<br>1100-2000 |
| Каты көнкүреш калдыкларының гомуми микдары:<br>Җәмәгать биналарын исәпкә алып | 280-300 | 1400-1500 |
| Сыек калдыкны көрәп (агызып) чыгару (канализация булмаганда) | - | 2000-3500 |

5.6.3. Контер мәйданчыкларын торак йортлардан, балалар, дәвалау-профилактика учреждениеләреннән, спорт мәйданчыкларыннан һәм халыкның ял итү урыннарыннан кимендә 20 метр ераклыкта урнаштырырга кирәк.

5.6.4. Бер мәйданчыкта урнашкан чүп-чар контейнерлары саны 5 тән артмаска тиеш.

5.6.5..Торак төзелешләре территориясендә сыек көнкүреш калдыкларын җыю өчен үзәкләштерелгән ташландык суларны агызу системасы белән тәэмин ителмәгәндә юынтык суларны түгү өчен ишегалларында чокырларны күздә тотарга кирәк.

**5.7. Төзекләндерү һәм яшелләндерү объектларына авыл җирлеге халкының норматив ихтыяҗларын билгеләүгә, күрсәтелгән объектларны урнаштыруга тәкъдимнәр**

5.7.1. Торак пункт төзелеше чикләрендә төрле билгеләнештәге яшелләндерелгән территорияләрнең чагыштырма авырлыгы (төзелеш территориясен яшелләндерү дәрәҗәсе) 5% тан да ким булмаска тиеш.

Төрле билгеләнештәге яшелләндерелгән территорияләр дигәннән гомуми һәм чикләнгән яшелләндерелгән территорияләрне, сибелгән орлыклардан үзләре үсеп чыккан агач һәм куак утыртмаларын, торак пунктлар территорияләрендәге урманнарны аңларга кирәк.
5.7.2. Торак пункттагы яшел утыртмаларныв, аның планлаштыру структурасын һәм җирле шартларын исәпкә алып, бердәм система рәвешендә карарга кирәк.
Торак пунктның яңа территорияләрен проектлаганда һәм реконструкцияләгәндә гамәлдәге яшел утыртмаларны максималь рәвештә саклауны һәм куллануны күздә тотарга кирәк.
5.7.3. Гомуми кулланылыштагы яшелләндерү объектлары мәйданнарын түбәндәге күләмдә (үлчәмдә) кабул итәргә кирәк:
парклар – 10 га дан ким түгел;
бакчалар – 3 га дан ким түгел;
скверлар – 0,5 га.
5.7.4. Торак пунктлар территориясендә төзекләндерү һәм яшелләндерү объектларын урнаштыру принциплары, объектларның параметрларын СП42.13330.2011 Актуальләштерелгән редакция СНиП 2.07.01-89*. “Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру”ның 9 бүлеге нигезендә кабул итәргә кирәк.

**5.8. Зиратларны урнаштыруга тәкъдимнәр**

5.8.1. Бу бүлектә мәетне яки мәрхүмнең җәсәден җир куенына иңдерү юлы белән традицион күмелгән зиратларны урнаштыруга карата таләпләр һәм рекомендацияләр (тәкъдимнәр) китерелә.
5.8.2. Зират өчен җир кишәрлегенең үлчәмнәре 40 гектардан артмаска тиеш.
5.8.3. Зиратны урнаштырганда халык санының перспективадагы үсешен, үлем-китем коэффициентын, гамәлдәге зиратларның булуын, бер кабергә тиешле җир бүлемтеге нормасын исәпкә алырга кирәк.
5.8.4. Зиратларны торак пунктларның торак төзелеше территориясенә карата җилләрнең гадәттә кире якка исүен исәпкә алып урнаштырырга кирәк.
5.8.5. Яңа җирләү урыннары булдыру, гамәлдәге җирләү урыннарын реконструкцияләү экологик һәм санитар-гигиена экспертизасының уңай бәяләмәсе булганда мөмкин.
5.8.6. Авыл зиратларын торак, җәмәгать биналарыннан, спорт-сәламәтләндерү һәм санатор-курорт объектларыннан кимендә 50 метр ераклыкта урнаштырырга кирәк.
5.8.7. Зират өчен бирелгән кишәрлек (җир бүлемтеге) түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:
торак пункттан, ачык сулыклардан һәм агымсу юлларыннан капма-каршы якка авышу;
су басу зонасыннан читтә урнашу;
грунт суларының җир өстеннән кимендә 2,5 метр тирәнлектә булуы;
1,5 м тирәнлегендә коры (артык дымлы булмаган) уалучан туфрак (комлы) булу, 6 - 18% тирәсендә туфрак дымлылыгы белән.
5.8.8. Зиратлар территориясендә юл челтәрен, су сиптерү өчен суүткәргеч яки шахта коеларын, тышкы яктыртуны күздә тотарга кирәк.
5.8.9. Җирләү өчен кишәрлекләр үлчәмнәрен 14 нче таблица нигезендә кабул итәргә кирәк.

Таблица 14

| Бер урында бер дәрәҗәдәге җирләүләр саны | Кабернең зурлыгы киңлеге, метрларда | Кабернең зурлыгы буе, метрларда |
|---|---|---|
| 1 | 1,0 | 2,0 |
| 2 | 1,8 | 2,0 |
| 3 | 2,6 | 2,0 |
| 4 | 3,6/1,8 | 2,0/4,0 |
| 5 | 2,6 | 4,0 |
| 6 | 2,6 | 4,0 |

# 6. ИСӘП-ХИСАП КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕН НИГЕЗЛӘҮ БУЕНЧА МАТЕРИАЛЛАР

6.1. Нормативлар түбәндәге норматив хокукый актлар таләпләренә туры китереп әзерләнде:
Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы: 29.12.2004 ел, №190-ФЗ;
2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон;
1996 елның 12 гыйнварындагы “Җирләү һәм мәет кую эше турында”8-ФЗ номерлы Федераль закон;
“Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында” 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;
“2014 елга кадәр җәмәгать инфраструктурасы, социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителешнең социаль гарантияләре дәрәҗәсен билгеләү турында” 2009 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары
(30.05.2013 елга булган үзгәрешләр белән).
6.2. Нормативларны әзерләгәндә түбәндәге норматив документлар файдаланылды:
СП 42.13330.2011 Актуальләштерелгән редакция СНиП 2.07.01-89*. “Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү”;
СП 31.13330.2012 Актуальләштерелгән редакция СНиП 2.04.02-84* “Су белән тәэмин итү. Тышкы челтәрләр һәм корылмалар”;
СП 32.13330.2012 Актуальләштерелгән редакция СНиП 2.04.03-85* “Канализация.
Тышкы челтәрләр һәм корылмалар”;
СП 59.13330.2012 Актуальләштерелгән редакция СНиП 35-01-2001 “Халыкның азмобиль төркемнәре өчен биналар һәм корылмаларга үтүнең мөмкин булуы”;
СанПиН 42-128-4690-88 “Торак урыннары территорияләрен тоту буенча санитар кагыйдәләр”;
СанПиН 2.1.1279-03 “Зиратларны, биналарны һәм мәет җирләүгә аталган корылмаларны урнаштыруга һәм тотуга гигиеник таләпләр”;
Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1999 елның 19 октябрендәге 1683-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган социаль инфраструктура объектларына Россия Федерациясе субъектларының норматив ихтыяҗын билгеләү методикасы;
МДК 11-01.2002 “Россия Федерациясендә мәет кую һәм зиратларны карап тоту тәртибе турында тәкъдимнәр”;
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 27 декабрендәге 1071 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы шәһәр төзелешен проектлаштыруның республика нормативлары;
Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативлары.
6.3. Нормативлар әзерләгәндә исәпкә алынды:
авыл җирлегенең административ-территориаль төзелеше;
авыл җирлегенең социаль-демографик составы һәм халыкның тыгызлыгы;
табигать-климатик шартлар;
Рус Әшнәге авыл җирлегенең һәм Балык Бистәсе муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш программалары;
авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш фаразы;
җирле үзидарә органнарының һәм кызыксынган затларның тәкъдимнәре.
6.4. Җирлекнең җирле әһәмияттәге объектлары исемлеге, алар өчен нормативларның төп өлешендә авыл җирлеге халкының мөмкин булган минималь тәэмин ителеш дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре һәм авыл җирлеге халкы өчен мондый объектларның территориаль яктан мөмкин булган максималь мөмкин дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре билгеләнде, алар Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.2 маддәсендәге 4 өлешендә күрсәтелгән таләпләр, шулай ук нормативлар проектын эшләү буенча техник задание нигезендә билгеләнде.